РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » 06 2023 г. №811

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 01.10.2021 № 792 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш вазгыятьләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, 1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 декабрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 01.10.2021 ел, № 792 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм

гадәттән тыш вазгыятьләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы карарларына һәм боерыкларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина